**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**Исполнительный комитет**
**Урсаевского сельского**
**поселения Азнакаевского**
**муниципального района**

ул. Центральная, д. 65, село Урсаево,
Азнакаевского муниципального района,
423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Азнакай муниципаль районы**
**Урсай авыл**
**җирлеге башкарма комитеты**

Үзәк урам, 65, Урсай авылы
Азнакай муниципаль районы, 423318
Тел. (факс) (8-85592) 35-0-36

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«27» июня 2017 ел. № 5

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге
152-ФЗ номерлы Федераль законда каралган бурычларны
үтәүгә юнәлдерелгән чараларны гамәлгә ашыру турында

"Шәхси мәгълүматлар турында" 2006 елның 27 июлендәге 152-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 152-ФЗ номерлы Федераль закон) һәм "шәхси мәгълүматлар турында "Федераль законда һәм аның нигезендә кабул ителгән норматив хокукый актларда каралган бурычларны үтәүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген раслау хакында" 21.03.2012 елгы 211 номерлы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, карар бирәм:

1. Расларга:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси белешмәләрне эшкәртү кагыйдәләре (1 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында субъектларның яисә аларның вәкилләренең шәхси белешмәләрдән файдалану өчен сoратуларын карау кагыйдәләре (2 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси белешмәләрне эшкәртүнең шәхси белешмәләрне яклауга карата таләпләргә туры килүенә эчке контрольне гамәлгә ашыру кагыйдәләре (3 нче кушымта);
- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси мәгълүматлар шәхессез калган очракта шәхессез белешмәләр белән эшләү кагыйдәләре (4 нче кушымта);
- Муниципаль хезмәткәрләрнең шәхси белешмәләр эшкәртелә торган биналарга керү тәртибе (5 нче кушымта);

- Муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Урсай авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль вазыйфаларын биләүче затларның шәхси белешмәләрне эшкәртүне йә шәхси белешмәләрдән файдалануны күздә тоткан вазыйфалары исемлеге (6 нчы кушымта);

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетында шәхси белешмәләрне эшкәртүне оештыру өчен җаваплы вазыйфаи затның вазыйфаи регламенты (7 нче кушымта);

2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге башкарма комитетына:

- муниципаль хезмәткәрләрне әлеге карар һәм Үрнәк рәвешләр белән таныштыру (шәхси белешмәләрне эшкәртү кагыйдәләренә 1-3 нче кушымталар);

- муниципаль хезмәткәрләргә (хезмәткәрләргә) Россия Федерациясе законнарының шәхси белешмәләрне эшкәртүгә бәйле таләпләрен үтәмәүнең хокукый нәтиҗәләрен аңлатырга;

- муниципаль хезмәткәрләрнең һәм Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты хезмәткәрләренең Россия Федерациясенең шәхси белешмәләр өлкәсендәге норматив хокукый актлары белән танышуы;

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урсай авыл җирлеге Башкарма комитетының шәхси белешмәләрне эшкәртүне турыдан-туры гамәлгә ашыручы муниципаль хезмәткәрләре (хезмәткәрләре) тарафыннан, алар белән хезмәт контракты яисә хезмәт шартнамәсе өзелгән очракта, вазыйфаи (хезмәт) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә аңа билгеле булган шәхси белешмәләрне эшкәртүне туктату йөкләмәләрен рәсмиләштерү;

- муниципаль хезмәтләр күрсәтүгә һәм вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәрләрнең (хезмәткәрләрнең), шулай ук башка субъектларның шәхси белешмәләрен эшкәртүгә ризалык рәсмиләштерү;

- муниципаль хезмәткәрләргә (хезмәткәрләргә) Россия Федерациясенең шәхси белешмәләрне эшкәртүгә бәйле законнары таләпләрен үтәмәүнең хокукый нәтиҗәләрен аңлату һәм шәхси белешмәләрне бирүдән баш тартуны аңлатуны рәсмиләштерү чараларын үткәрү.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Башлык: И.А.Абдуллин